ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

21 декабря 2018 г. № 7676

Җир эшләрен башкаруга ордер бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрдән файдаланганда гражданнарның остәмә гарантияләрен билгеләү өлешендә «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 19 июлендәге 204-ФЗ санлы Федераль закон, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 нче карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезнамәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2013 елның 18 июнендәге 3630 нчы карары белән (Башкарма комитетның 2013 елның 19 декабрендәге 7673 нче, 2016 елның 23 июнендәге 3201 нче, 2018 елның 22 июнендәге 3599 нчы карарлары редакциясендә) расланган җир эшләрен башкаруга ордер бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1.3.1 пунктның икенче абзацындагы «239 кабинет» сүзләрен «253 кабинет» сүзләренә алмаштырырга;

2) 1.4 пунктның унөченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- Башкарма комитетның 2017 елның 11 июнендәге 674-р санлы боерыгы белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе турында нигезнамә (алга таба – Идарә турында нигезнамә);»;

3) 3.3.2 пунктта:

- сигезенче абзацтагы «Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасарына» сүзләрен «Башкарма комитет Җитәкчесенә» сүзләренә алмаштырырга;

- унөченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Процедураларның нәтиҗәсе: кабул ителгән, теркәлгән һәм карап тикшерү өчен Башкарма комитет Җитәкчесенә җибәрелгән яки гариза бирүчегә кире кайтарылган документлар.»;

4) 3.3.3 пунктның беренче абзацындагы «Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары» сүзләрен «Башкарма комитет Җитәкчесе» сүзләренә алмаштырырга;

5) 3.5.1 пунктта:

- дүртенче абзацтагы «Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасарына» сүзләрен «Башкарма комитет Җитәкчесенә» сүзләренә алмаштырырга;

- алтынчы абзацтагы «Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасарына» сүзләрен «Башкарма комитет Җитәкчесенә» сүзләренә алмаштырырга;

- җиденче абзацтагы «Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары» сүзләрен «Башкарма комитет Җитәкчесе» сүзләренә алмаштырырга;

6) 4.2 пункттагы «Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары» сүзләрен «Башкарма комитет Җитәкчесе» сүзләренә алмаштырырга;

7) 4.4 пунктның икенче абзацындагы «Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары» сүзләрен «Башкарма комитет Җитәкчесе» сүзләренә алмаштырырга;

8) 3.8.3 пунктның беренче абзацындагы «3.3.4,» цифрларын төшереп калдырырга;

9) 5.1 пунктта:

- 3 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3) муниципаль хезмәт күрсәтү өчен гариза бирүчедән Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең норматив хокукый актларында тапшыру яки гамәлгә ашыру каралмаган документлар яки мәгълүмат яисә эшләрне гамәлгә ашыруны таләп итү;»;

- түбәндәге эчтәлектәге унбишенче, уналтынчы абзацлар белән тулыландырырга:

«10) муниципаль хезмәт күрсәткәндә гариза бирүчедән 210-ФЗ санлы Федераль законның 7 маддәсендәге 1 бүлекнең 4 пунктында каралган очраклардан тыш, муниципаль хезмәт күрсәтүдән яисә муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән беренчел баш тартканда булмавы һәм (яки) дөрес булмавы күрсәтелмәгән документларны яки мәгълүматны таләп итү.

210-ФЗ санлы Федераль законның 16 маддәсенең 1.3 бүлегендә билгеләнгән тәртиптә, карарларына һәм эш итүләренә (эш итмәүләренә) шикаять бирелә торган күпфункцияле үзәккә тулы күләмдә тиешле дәүләт яки муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча функция йөкләнгән булса, күрсәтелгән очракта гариза бирүче тарафыннан күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарларына һәм эш итүләренә (эш итмәүләренә) судка кадәр (суддан тыш) шикаять бирелергә мөмкин.»;

10) 5.8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.8. Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш дип танылган очракта, гариза бирүчегә әлеге регламентның 5.7 пунктында күрсәтелгән җавапта,

муниципаль хезмәт күрсәткәндә ачыкланган кимчелекләрне тиз арада бетерү максатында Башкарма комитет, күпфункцияле үзәк яисә 210-ФЗ санлы Федераль законның 16 маддәсенең 1.1 бүлегендә каралган оешма тарафыннан гамәлгә ашырыла торган эшләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук тудырылган уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә һәм муниципаль хезмәттән файдалану максатында гариза бирүче башкарырга тиешле алдагы гамәлләр турында мәгълүмат күрсәтелә.

Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш түгел дип танылган очракта, гариза бирүчегә әлеге регламентның 5.7 пунктында күрсәтелгән җавапта кабул ителгән карар сәбәпләре турында дәлилләнгән аңлатмалар, шулай ук кабул ителгән карарга шикаять бирү тәртибе турында мәгълүмат бирелә.»;

11) 1 нче кушымтаны әлеге карарга 1 нче кушымтада каралганча яңа редакциядә бәян итәргә;

12) 2 нче кушымтаны төшереп калдырырга.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында рәсми бастырып чыгаруны һәм «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасары И.С. Зуевка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе

Р.Ә. Абдуллин

Башкарма комитетның
2018 елның 21 декабрендәге
7676 нчы карарына
кушымта

Җир эшләрен башкаруга ордер бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына
1 нче кушымта

Башкарма комитет
Җитәкчесенә

____________________________________________
(физик затның Ф.И.А.и., юридик затның исеме, ОГРН - юридик зат өчен)

____________________________________________
(яшәү урыны/урнашу урыны, элемтә телефоннары)

Гариза

______________________________________________________ объектта
(объектның исеме, адресы, җир участогының кадастр номеры)
_________________________________________________________ өчен
(башкарыла торган эшләрнең төре)
җир эшләрен башкаруга ордер бирүегезне сорыйм.
Эшләр «__» ________ 20_ елдан «__» _______20_ елга кадәр башкарылачак.
Подрядчы ____________________________________________________
(подрядчы оешманың исеме)
Җир эшләрен башкаруга җаваплы: _________________________________
(вазыйфасы, фамилиясе, исеме, атасының исеме, телефон)
«__» __________ 20__ ел

Вәкаләтле затның
вазыйфасы
(юридик затлар өчен) ___________________ ________________________
имза имза расшифровкасы

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе Г.К. Әхмәтова